| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2015 г.Казань № 01-02/170

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмә тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасындагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә һәм "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру буенча чаралар турында" 2010 елның 30 сентябрендәге Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен һәм вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва иткән гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырулары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырулары турында" 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфаны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык

хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге УП-329 номерлы Указын тормышка ашыру максатында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларының исемлеген расларга (алга таба – Вазыйфалар исемлеге).

2. Вазыйфалар исемлегенә түбәндәге вазыйфаи бурычларны башкарырга тиешле вазыйфалар кертелүен билгеләргә:

даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләргә яраклы рәвештә власть вәкиле функциясен, шулай ук, оештыру-эш йөртү яки административ-хуҗалык функцияләрен башкару;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәте күрсәтү;

бюджет ассигнованиеләрен бүлү буенча карарлар әзерләү һәм кабул итү;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү;

дәүләти сатып алуларны башкару һәм башкарырга рөхсәт бирү;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

3. Вазыйфалар исемелегенә кертелгән вазыйфаны биләгән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12нче маддәсенә ярашлы рәвештә түбәндәгеләрне аңлатырга:

Министрлыкта Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин, әгәр әлеге оешма дәүләт идарәсенең аерым функцияләре дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи (хезмәттәге) таләпләренә кергән булса, дәүләт гарждан хезмәткәрләренә булган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Министрлык Комиссиясе ризалыгы белән, дәүләти гражданлык хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә, хезмәт яки гражданлык-хокукый килешү шартларында, оешмада вазыйфа биләргә яисә әлеге оешмага бер ай дәвамында гражданлык-хокукый килешү (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында йөз мең сумнан артык күләмдәге эш башкарырга хокуклы;

Министрлыкта Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин, дәүләти гражданлык хезмәтеннән азат ителгәннән соң ике ел эчендә, эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турындагы

гражданлык-хокукый килешү төзегәндә, эш бирүченең вәкиленә үзенең соңгы хезмәт итү урыны турында хәбәр итәргә тиеш;

Министрлыкта Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның, дәүләти гражданлык хезмәтеннән азат ителгәннән соң, бу пунктның өченче абзацында каралган таләпне үтәмәве әлеге пунктның икенче абзацындагы эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен әлеге граждан белән төзелгән хезмәт килешүен яки гражданлык-хокукый килешүне өзүгә китерә;

4. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә (Слепнева Э.И.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

5. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.) “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтына, “Коррупциягә каршы тору” бүлегенә урнаштырырга.

6. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (Гәрәев М.М.) Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

7. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупция куркынычы белән бәйле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге”; 20 январь, 2010 ел, № К-3/03-03;

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупция куркынычы белән бәйле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” 8 февраль, 2010 ел, № К-3/03-03;

“ТР Юстиция министрлыгының 20.01.2010 ел, № К-3/03-03 боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 30 сентябрь, 2010 ел, № К-141/03-03;

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупция куркынычы белән бәйле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” 7 июнь, 2012 ел, № К-79/03-03;

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупция куркынычы белән бәйле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” 9 ноябрь, 2012 ел, № К-139/03-03;

“ТР Юстиция министрлыгының 20.01.2010 ел, № К-3/03-03 боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 24 июнь, 2013 ел, № К-83/03-03;

“ТР Юстиция министрлыгының 20.01.2010 ел, № К-3/03-03 боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 29 август, 2013 ел, № К-110/03-03;

“Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының коррупция куркынычы белән бәйле Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” ТР Юстиция министрлыгының 20.01.2010 ел, № К-3/03-03 боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 17 февраль, 2014 ел, № К-28/03-03.

8. Татарстан Республикасы дәүләт сатып алулары идарәсе җитәкчесенең 2012 елның 11 апрелендәге №06-15-68 Боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

9. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы Юстиция
министрлыгы боерыгы белән расланган

“ 11 ” март 2015 ел. № 01-02/170

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының, вазыйфалары коррупция куркынычы белән бәйле булган, шуңа күрә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларын үтәгәндә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалар

ИСЕМЛЕГЕ

1. Югары төркем вазыйфаларының “җитәкче” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Юстиция министрының беренче урынбасары;

Юстиция министрының урынбасары.

2. Әйдәп баручы төркем вазыйфаларының “ярдәмче (киңәшче)” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Министр ярдәмчесе.

3. Баш төркем вазыйфаларының “җитәкче” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

эшләр белән идарә итүче;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге начальнигы

финанс бүлеге начальнигы;

хокукый экспертиза һәм нормалар чыгару эшчәнлеге бүлеге начальнигы

норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге начальнигы

хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге начальнигы

җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге начальнигы

җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру һәм хокукый тәэмин итү бүлеге начальнигы

мәгълүмати-аналитик эшчәнлек, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге начальнигы

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге начальнигы

җирле үзидарә органарына хокукый консультацтон-методик ярдәм бүлеге начальнигы

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлеге начальнигы

оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге

4. Әйдәүче төркем вазыйфаларының “җитәкче” категориясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

финанс бүлеге начальнигы урынбасары;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге начальнигы урынбасары

хокукый экспертиза һәм нормалар чыгару эшчәнлеге бүлеге начальнигы урынбасары

хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге начальнигы урынбасары

җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге начальнигы урынбасары

мәгълүмати-аналитик эшчәнлек, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге начальнигы урынбасары

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү секторы мөдире

түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы мөдире

Килешенгән:

Министрның беренче урынбасары
Р.И.Заһидуллин

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге начальнигы
М.М.Гәрәев

Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге начальнигы

Э.И.Слепнева

Боерыкны әзерләде:

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәүче консультанты
А.А.Мухачев